**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**«ЯҢА ТРОИЦКИЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

20.06.2016 7/1

# КАРАР

Киткән хатаны төзәтү турында

Яңа Троицкий авыл җирлегенең 2016 елның 3 февралендәге 5/2 номерлы карарының 2 өлешендә, 2016 елның 27 мартындагы 6/17 номерлы карарының 2 өлешендә киткән хата белән бәйле рәвештә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Җирле референдум турында» 2004 елның 25 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 12 статьясы, Яңа Троицкий авыл җирлеге уставы нигезендә муниципаль берәмлек Советы

КАРАР БИРДЕ:

1. Яңа Троицкий авыл җирлегенең 2016 елның 3 февралендәге 5/2 номерлы карарының 2 өлеше «а» пунктын түбәндәгечә укырга:
а) Суровка авылы 1 нче округ
- балалар мәйданчыгын урнаштыру һәм төзекләндерүгә - 30000 сум,
- урам яктырту приборларын ремонтлауга һәм урнаштыруга - 9100 сум.
2. Яңа Троицкий авыл җирлегенең 2016 елның 27 мартындагы 6/17 номерлы карарының 2 өлеше 1 пунктын түбәндәгечә укырга:
1) Я Суровка авылы 1 нче округ
- балалар мәйданчыгын урнаштыру һәм төзекләндерүгә - 30000 сум,
- урам яктырту приборларын ремонтлауга һәм урнаштыруга - 9100 сум.
3. Әлеге карарны «Якты юл»-«Светлый путь» газетасында бастырырга.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында һәм Тукай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
5. Әлеге карар басылып чыккан көннән үз көченә керә.

Муниципаль берәмлек башлыгы,
Совет рәисе Р.Р. Волкова